**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Глава
Алькеевского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

Пер.Советский,44а, с.Алькеево
423309 тел. ( 885592) 37-4-23

**Alk.Azn@tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Әлкщй авыл жирлеге
советы
БАШЛЫГЫ

Совет тыкрыгы, 44а
Әлкәй авылы, 423309
тел. (885592) 37-4-23
**Alk.Azn@tatar.ru**


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**15.10.2025 ел** **№3**

Татарстан Республикасы Азнакай муници аль районы Әлкәй авыл җирлегенең Кызыл Сукачы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасынд җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Р спубликасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елның 01 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Кызыл Сукачы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Кызыл Сукачы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы -Татарста Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма ком теты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2025 елның 01 ноябрендә, 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны - Кызыл Сукачы авылы, Чапаев ур., 26 йорт (Галимов Илшат Таһир улы йорты каршындагы урамда)

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 16 октябреннән дә соңга калмыйча. гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Башкарма

комитетында түбәндәге адрес буенча: Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а, Кызыл Сукачы авылы, Чапаев ур., 26 йорт янындагы мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә.

- Кызыл Сукачы авылы торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Кызыл Сукачы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Кызыл Сукачы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (территориядәге юлларны кардан чистарту);

- ремонт, коймаларны кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (материал сатып алу һәм зират коймасын урнаштыру).

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а йорт (Башкарма комитетның административ бинасы); Әлкәй авылы, Совет урамы, 34 йорт (авыл мәдәният йорты), Кызыл Сукачы авылы, Чапаев ур., 26а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Әлкәй авыл җирлеге башлыгы А.Н.Арсланов

АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛЬКЕЕВСКОГО СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002494
КПП 164301001